Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**2010 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 3 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

1. 2010 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба – Фонд) бюджетының төп тасвирламаларын түбәндәгечә расларга:

1) Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен – 18 409 711,9 мең сум, шул исәптән Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән – 1 478 647,9 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 9 615 581,0 мең сум, Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары бюджетларыннан 3 300 273,0 мең сум итеп;

2) Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 18 745 603,7 мең сум итеп;

3) Фонд бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 335 891,8 мең сум итеп.

2. 2010 елга Фонд бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганакларын әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

**2 статья**

1. Фонд бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Фонд бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

**3 статья**

2010 елга Фонд бюджеты керемнәре әлеге Законга 4 нче кушымтада күрсәтелгән күләмнәрдә салым һәм салым булмаган керемнәр, шул исәптән территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетына күчерелә торган мәҗбүри медицина иминиятенә иминият кертемнәре, һәм кире кайтарылмый торган суммалар исәбеннән формалаштырыла дип билгеләргә.

**4 статья**

2010 елга Фонд бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 статья**

1. Сәламәтлек саклау учреждениеләрен Татарстан Республикасы бюджетыннан, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларыннан Фонд тарафыннан алына торган акчалар исәбеннән мәҗбүри медицина иминияте системасы аша өстенлекле нигездә бер каналлы финанслауны дәвам итәргә.

2. Бюджетара трансфертлар күрсәткечләрендә 2010 елга мәҗбүри медицина иминияте системасы аша өстенлекле нигездә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларыннан Фонд бюджетына тапшырыла торган акчаларның түбәндәге күләмнәрдә чагылдырылган булуын исәпкә алырга:

Татарстан Республикасы бюджетыннан 4 582 306,0 мең сум күләмендә;

муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларыннан әлеге Законга 6 нчы кушымта нигезендә 3 300 273,0 мең сум күләмендә.

3. 2010 елда сәламәтлек саклау учреждениеләрен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша өстенлекле нигездә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларыннан күчерелүче кире кайтарылмый торган суммаларны Фонд бюджетына күчерү ай саен 20сенә кадәр гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

**6 статья**

Фонд бюджетын әлеге Законда расланганнан артыграк итеп үтәү нәтиҗәсендә фактта алынган һәм максатчан характерда булган бюджетара

трансфертлар, әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә генә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертеп, бюджетара трансфертлар бирелә торган тиешле максатларга чыгымнарны арттыруга җибәрелә дип билгеләргә.

**7 статья**

2010 елга нормалаштырылган иминләштерү запасы мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелгән төрләр буенча Россия Федерациясе гражданнарына иминият территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәменә территорияара исәп-хисапларын финанслау өчен 115 000,0 мең сум күләмендә формалаштырыла дип билгеләргә.

**8 статья**

Эшләүче гражданнарга өстәмә диспансеризация үткәрүгә, стационар учреждениеләрдә торучы ятим балаларга һәм авыр тормыш хәлендә булган балаларга диспансеризация үткәрүгә Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты ассигнованиеләрен 2009 елда тулысынча файдаланмау нәтиҗәсендә Фонд бюджетында 2010 елның 1 гыйнварына калган акчалар 2010 елда Фонд тарафыннан шул ук максатлар өчен тотылачак.

**9 статья**

Муниципаль берәмлекләрнең беренчел медицина-санитария ярдәмен күрсәтүче сәламәтлек саклау учреждениеләренең участок табиб-терапевтлары, участок табиб-педиатрлары, гомуми практика табиблары (гаилә табиблары), участок табиб-терапевтларының, участок табиб-педиатрларының участок шәфкать туташлары, гомуми практика табибларының (гаилә табибларының) шәфкать туташлары тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә медицина ярдәмен күрсәтүгә дәүләт йөкләмәсен финанс белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган ассигнованиеләрне 2009 елда тулысынча файдаланмау нәтиҗәсендә Фонд бюджетында 2010 елның 1 гыйнварына калган акчалар Фонд тарафыннан 2010 елның беренче кварталында 2009 елгы исәп-хисапларны түгәлләүгә тотылачак. Файдаланылмаган акчалар билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

**10 статья**

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлау һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләрен күрсәтү программасын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнованиеләрне 2009 елда тулысынча файдаланмау нәтиҗәсендә Фонд бюджетында 2010 елның 1 гыйнварына калган акчалар 2010 елның беренче кварталында 2009 елгы исәп-хисапларны түгәлләүгә җибәрелә. Файдаланылмаган акчалар Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

**11 статья**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Фонд бюджеты керемнәрен һәм чыгымнарын исәпкә алу, үтәү системасын өештыруны һәм аның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәргә тиеш.

Фонд бюджетының үтәлеше Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Фонд акчаларыннан максатка яраксыз файдаланган өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылык билгеләнә.

**12 статья**

Әлеге Закон 2010 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2009 елның 17 декабре
№ 65-ТРЗ